| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 апрель 2014 ел Казан шәһәре № 7-8/т

***"Татфлот" суднолар йөрү компаниясе" ААҖ тарафыннан Тәтеш шәһәре территориясендә урнашкан причалны биреп тору буенча хезмәт күрсәтүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифны билгеләү турында***

"Табигый монополияләр турында" 17 август, 1995 ел, № 147-ФЗ Федераль законга, "Транспорт терминалларында, портларда, аэропортларда табигый монополияләр субъектлары хезмәтләре күрсәтүгә һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану хезмәтләре күрсәтүгә бәяләрне (тарифлар, җыемнар) дәүләти җайга салу һәм контрольдә тоту турында" 23 апрель, 2008 ел, № 293 һәм "Табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеген дәүләти җайга салуны һәм контрольлекне хәл итүдә тарифларны дәүләти җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының катнашуы турында" 10 декабрь, 2008 ел, № 950 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь, 2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР бирә:

1. Бу карарга кушымта нигезендә, "Татфлот" суднолар йөрү компаниясе" ААҖ тарафыннан Тәтеш шәһәре территориясендә урнашкан причалны биреп тору буенча хезмәт күрсәтүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифны билгеләргә.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
кушымта
18 апрель 2014 ел № 7-8/т

## “Татфлот” суднолар йөрү компаниясе” ААҖ тарафыннан Тәтеш шәһәре территориясендә урнашкан причалны биреп тору буенча хезмәт күрсәтүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| № п/п | Хезмәт күрсәтү төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф |
|---|---|---|---|
| 1. | Йөк операцияләрен башкармыйча гына судно куеп тору өчен причал бирү | Судноның габарит озынлыгының 1 метры өчен сум./сәг. | 15 |

Искәрмәләр:

1. “Татфлот” суднолар йөрү компаниясе” ААҖ тарафыннан Тәтеш шәһәре территориясендә урнашкан причалны биреп тору буенча хезмәт күрсәтүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифны куллану Россия Федерациясе законы нигезендә хәл ителә.
2. “Татфлот” суднолар йөрү компаниясе” ААҖ клиентлар белән килешүләр төзегәндә максималь дәрәҗәдә чик тарифны яки аннан кимрәк тарифны куллануга хокуклы.
3. Максималь дәрәҗәдә чик тариф өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге